| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШАЛТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАЛТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 февраль 2020ел с.Шалты № 5

Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан махсус инвестицияле контрактлар төзү Тәртибен раслау турында

Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 31.12.2014 ел, №488-ФЗ Федераль законның 16 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ :

1. Түбәндәге кушымталарны расларга

- Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан махсус инвестицияле контрактлар төзү Тәртибе (1 нче кушымта);

- махсус инвестицияле контракт төзү буенча инвесторның гаризасы формасы (2 нче кушымта);

- махсус инвестицион контрактлар төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссия эшчәнлеген формалаштыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе З.Х. Фаткуллин